РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » 07 2021ел №526

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 1032 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 04 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 08 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, һәм спортның культивацияләнә торган төрләрен үстерү өчен шартлар тудыру, җыелма командаларны формалаштыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының конкурентлыкка сәләтле спорт абруен күтәрү һәм ныгыту максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 1032 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик

культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны эшләү өчен нигез» бүлегендә «Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт турында» 1999 елның 01 декабрендәге 2476 номерлы Законны «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 08 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына алмаштырырга;

1.2. «Программаны еллар буенча бүлеп финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар буенча бүлеп финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслау муниципаль, республика бюджетлары һәм җәлеп ителгән акчалар исәбеннән башкарыла. |

| Программаны гамәлгә ашыру еллары | 1 нче ел/ мең сум. | 2 нче ел/ мең сум. | 3 нче ел/ мең сум. | Барлыгы мең сум. |
|---|---|---|---|---|
| Барлык чыганаклар буенча | 24 656,89 | 31 60,68 | 31137,17 | 86  854,74 |
| Ютазы муниципаль районы бюджеты һәм авыл җирлекләре бюджетлары акчаларыннан, шулардан: | 21 098,8 | 28 501,1 | 28 667,7 | 78 267,6 |
| - Спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорснг | 0,00 | 0,00 | 2,38 | 2,38 |
| Спорт чаралары | 1 018,7 | 324,2 | 95,7 | 1 438,6 |
| Татарстан Республикасы - бюджеты исәбеннән, шулардан: | 186,99 | 288,88 | 473,77 | 949,64 |
| - Спорт мәктәпләрен җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | 186,99 | 199,65 | 235,75 | 622,39 |
| - Спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре | 0,00 | 89,23 | 238,02 | 327,25 |
| Җәлеп ителгән өстәмә акчалар | 2 352,4 | 1 946,5 | 1 900,0 | 6 198,9 |

Ютазы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 78 020,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:
2019 елда -21 042,8 мең сум
2020 елда - 28 405,5 мең сум.
2021 елда -28 572,1 мең сум
Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге бюджеты

| | |
|---|---|
| | акчалары исәбеннән 20,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 5,0 мең сум<br>2020 елда -7,6 мең сум<br>2021 елда -7,6 мең сум<br>Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән - 10,1 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда - 1,7 мең сум.<br>2020 елда - 4,2 мең сум.<br>2021 елда - 4,2 мең сум.<br><br>Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 31,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда -9,0 мең сум<br>2020 елда - 11,1 мең сум<br>2021 елда - 11,1 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 22,5 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда -7,5 мең сум<br>2020 елда -7,5 мең сум<br>2021 елда -7,5 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 21,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 0 мең сум<br>2020 елда - 10,6 мең сум<br>2021 елда - 10,6 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 29,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 9,8 мең сум<br>2020 елда - 9,8 мең сум<br>2021 елда - 9,8 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 12,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 0 мең сум<br>2020 елда - 6,4 мең сум<br>2021 елда - 6,4 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 16,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 5,6 мең сум<br>2020 елда - 5,6 мең сум<br>2021 елда - 5,6 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән 35,5 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 11,9 мең сум<br>2020 елда -11,8 мең сум<br>2021 елда -11,8 мең сум<br><br>Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге бюджеты акчалары |

| | |
|---|---|
| | исәбеннән 47,5 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда - 5,5 мең сум.<br>2020 елда - 21,0 мең сум.<br>2021 елда - 21,0 мең сум.<br><br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты һәм авыл җирлекләре бюджетлары проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Җирле бюджетларның һәм бюджеттан тыш чыганакларның акчалары ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 1032 номерлы карары белән расланган «2019-2021 елларга Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 1032 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
.Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Башкаручы Галләмова Р. А.
тел. (85593) 2-81-97